ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**08.02.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 234**

2022 елга салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, 2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак - коммуналь хуҗалык министрлыгының 2021 елның 17 декабрендәге «Россия Федерациясе буенча торак урынның гомуми мәйданының 2022 елның беренче яртыеллыгына бер квадрат метрының бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча 2022 елның I кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 955/пр номерлы боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2022 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 729 944 руб.;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 3 459 888 руб.;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 5 189 832 руб.;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 6 919 776 руб.;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 8 649 720 руб.;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 10 379 664 руб.;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 12 109 608 руб.

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 35 081,11 руб.;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 35 081,11 руб.;

1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 35 081,11 руб.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 елга гражданнар керемeнең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында» 2021 елның 19 апрелендәге 839 номерлы карарын, 2021 елның 02 июнендәге «2021 елның II кварталына гражданнар керемeнең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында» 1227 номерлы карарын, «2021 елның III кварталына гражданнар керемeнең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында»

2021 елның 16 сентябрендәге 2270 номерлы карарын, 2021 елның 02 декабрендәге «2021 елның IV кварталына салым салынырга тиешле граждannар кеременең һәм мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен раслау турында» 3084 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда «Зеленодольск муниципаль районының Торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне кулланырга.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

5. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев